Алып баручы. Бугенге кичәбез татар халкының бөек улы, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, патриот-шагыйрь- Муса Җәлилгә багышлана.

Без М.Җәлилнең батырлыгын искә алып телдән китап чыгарырбыз. Китабыбызның беренче бите “Батырлык кайдан башлана?” – дип атала.(Бәйрәм пр-я ярдәмендә үрелеп бара.)

Әйтче Муса,  мондый батырлыкны.

Кай җирендә саклап йөрттең?

Әйт син безгә.

Кайдан алдың син шундый горурлыкны?

Горурлык – это гордость.(Пр-я карау.)

А гордость – чувство собственного достоинства, уважения.

Горурлык – горурлану кисе, үзеңә хөрмәт кисе, үз дәрәҗәңне тою” дилгән сүз.

А. Б. М. Җәлилнең туган җире – Оренбург өлкәсе-Мостафа авылы. Аның әтисе – Мостафа абый балаларын укытырга, белемле итәргә тырыша. Шуңадыр инде Муса 6 яшендә үк авыл мәдрәсәсендә укый башлый.

А.Б. Мусаның беренче укытучысы Габдулла Усманов менә нәрсә ди:

“Гарәп хәрефләрен Муса мәктәпкә килгәндә үк белә иде инде. Хәтере дисәң, ис китмәле. Аның классташлары әле яңа гына әлифне ятлап азапланалар, ә Муса инде шактый яхшы итеп укый һәм яза.Бер ай да узмады ул иптәшләрен узып китте. Шуннан аны икенче класска күчерергә туры килде.

Тагын ай ярым да узмагандыр, карый, бу малайга икенче класс материалы да артык җинел. Шулай итеп, уку елының урталарында инде ул өченче класска күчте, ә язга мәктәпнең барлык дүрт классын тәмамлап чыкты. Башка андый хәлнең булганын хәтерләмим.

А.Б. Мусаның әнисе Рәхима апа искиткеч сабыр холыклы, шигъри җаңлы кеше булган. Ул үзе дә шигырьләр язган, җырлар чыгарган.

Т. Миңнуллин “Моңлы бер җыр” пьесасыннан өзек сәхнәләштерү.

Шагыйрь  Исәнмесез!

Ана. Исәнмесез, балам!

Ш. Мин сезгә ничек эндәшергә дә белмим.

Ана. Рәхимә әбекәй дип әйтсәң килешер , балам.

Ш. Юк, мин сезгә алай гади итеп эндәшә алмыйм.

Ана. Син  үзең кем соң, балам?

Ш. Киләчәктән килдем сезнең янга.

Ана. Алай икән. Йомышың ни иде соң, бәбкәм?

Ш. Сез-М. Җ. Дөньяга бүләк иткән Ана.

Ана. Бүләк иттем дә менә, күрә алмый тилмерәм.

Ана күңеле-балада,

Бала куңеле-далада.

Шул сүз әле чамада,-

Уйлап карагыз, балам.

Үсәләр дә китеп югалалар, үсәләр дә китеп югалалар.

Ш. Балаларыгыз югалмады, бөек Ана.

Ана. Кайтмыйлар бит.

Ш. Исәннәре илгә хезмәт итә. Киткәннәре якты эз калдырып китте.

Ана. Муса улым кайларда йөри , белмисеңме?

Ш. Халык күңелендә.Сез дөньядан иртәрәк киттегез. Мусаның бөеклеккә ирешкәнен күрә алмый киттегез.

Ана.Рәхмәт әйт үзләренә,балам.Ил алдында әтиләрен,әниләрен хур итмәгәннәре өчен рәхмәт әйт.

Шагыйрь. Сөйләгез иде миңа Муса турында,бөек Аңа.

Ана. Ни сөйлим... Тапкач та ак биләүләргә биләдем, күкрәк сөтемне имездем.

Шагыйрь. Сез аңа бөеклеккә юл күрсәткәнсез.

Ана. Юлны Ил күрсәтте аларга,балам.Мин бары тик,яхшы булыгыз ,матур торыгыз!- гына дидем мин аңа.

А.Б. Шагыйрьнең сеңелесе Зәйнәп Җәлилова нәрсә ди:

Муса барысына да өлгерә иде, ди. Аның тәкъдиме белән авылда балалар китапханәсе ачтык,журналлар чыгара башладык,-ди.

1) Ук. 1919 ел Оренбург “Кызыл Йолдыз” газетасы редакциясе. 13 яшьлек Муса узенең беренче шигырен укый.

Кулыма мин кызыл кылычны алсам,

Шулай шуннан кызыл фронтка барсам,

...Бөтен күәт белән шунда сугышсам,

Җиңелми мин һаман да алга барсам,

...Менә шунда бәхетле мин, бәхет-шул,

...Шулай, эшчем, кораллан, бар сугышка.

Юлыңнан кайтма син,кирәк егыл-ул!

А.Б 22 елның көзендзә Казанга килә,редакциядә эшли, Рабфата укый.Ул шәһәрдә 6 ел тора бик үзгәрә, чиста киенә, русча җиңел сөйләшә башлый.

Соңгы елларда Мәскәүдә шул өйдәге квартирада яши.(приз-я карау).

1) Ук. Сугышка кадәр үк Муса Җәлил татар халкының күренекле шагыйре,җәмәгать эшлеклесе булып танылa.Шигырь, поэмалар иҗат итә,опералар өчен либретто яза.Аның “Алтынчәч” һәм “Илдар” либреттоларына композитор Нәҗип Җиһанов шул исемдәге опералар иҗат итә. Муса Җәлилнең күп кенә шигыре,композиторлар тарафыннан көйгә салынып, яратып башкарыла торган җырларга әверелә.”Сагыну”,”Җиләк җыйганда” кебек лирик җырлары бүгенгә кадәр яши,халык күңелен җылыта.

   А.Б  Китабыбызның 2 өлеше “Үлемсезлеккә юл дип атала.
   1941 ел. 22 июнь Бөек Ватан сугышы башлана.
   Сугышка барырга теләп Муса Җәлил 7 тапкыр гариза яза,Әнә шул турыда шигырь тыңлыйбыз,батырлыкка,улемсезлеккә илткән юл әнә шулай башлана.

1) Ук.
   Фашист керде басып җиребезгә,
   Аркасына асып балтасын...
   Ул яндыра, вата илебезне,
   Ничек шуңар түзеп ятасың?..

   Аргамагым, әйдә ,канатлан да,
   Җил булып оч сугыш  кырына.
   Җырым утын корыч сөңге итеп
   Мин күтәрдем хәзер кулыма.

   Әйдә,җырым, батыр җиңү дәртен
   Алып керик ялкын эченә.
   Мин калмасам җирдә,син калырсың
   Һәйкәл булып үлмәс эшемә.

   А.б. М.Җ-н Әминә Җәлилова язган шигыреннән өзекне Дима сөйли.
   3)Ук.
   Хуш ,акыллым ,әгәр кайталмасам,
   Яраланып юлда егылсам,
   Йөрәгемдә саклап ялкыныңны,
   Акрын-акрын тәнем суынса,
   Хуш ,акыллым!

   Тиздән мин кайтырмын,
   Бар вәхшәттән илем арынгач,
   Һәм күгендә бөек Туган илнең
   Җиңү таңы балкып кабынгач!

А.б.Менә аның сөекле Чулпанына язган хаты   “.Сөекле Чулпаным!”

Хатың өчен рәхмәт.Миңа андый хатларны күбрәк яз. Мин аларны укып шатланам.Походтан кайткач ,хатны күп итеп язармын.

Мин озак тормам инде,тиздән фашистларны тар-мар итәрбез дә кайтырмын.

Хат яз. Кысып үбәм. Әтиең.

А.б.Әтисе аны бик сагына.

Киткән чакта ,кызым нигә шулай

Күзләремә әрнеп карадың?

Сизденмени әткәң йөрәгенең

Синең янда өзелеп калганын.

Мин саклармын йөрәк каным белән,

Илемне һәм сезне, аппагым!

А. б. Муса Җәлил политрук итеп Волхово фронтына җибәрелә. "Отвага" армия газетасында хәрби хәбәрче булып эшли. Еш кына фронт сызыгында була. Сугыш туктап торган арада ул сугыш турында шигырьләр яза.

Кызыл ромашка шигырен сәхнәләштереп уйнау.

А.б. 1942 елда М.Җәлилнең хатлары килми башлый. 1942нче елда Волхов юнәлешендә барган сугышларда аларның часте чолганышта кала, ул каты яралана, әсирлеккә эләгә.

1 укучы. Ул дошманның үз оясында аңа каршы көрәш алып бара, яшерен оешма төзи.

2 укучы. Җәлилчеләрнең яшерен оешмасы эше бушка китми. Алар немецларны кырып-бетереп, Белорусия партизаннары ягына чыгалар.

А.б. Үлемсезлек юлы озынмы? Волховтан алып Гильотинага кадәр санасаң, 791 көн! Авыр, газаплы әсирлектә үткәргән 791 көн! Ул анда 93 шигырен яза.

Тоткынлыкта Җәлилчеләр М. Җәлил алдында авырлыкларга түзәргә ант иттеләр. Алар Курмаш, Хәсән, Алиш, Булатов һ.б. Алар бу турыда менә ни диләр:

1 бала. "Җәлилне без "Бөркет" дип йөри идек. Алишны "Бөркетнең уң канаты", Гайнанны, Кормашны "Сул канаты", яшерен оешма әгъзәләрен "Бөркет балалары" дип атый идек" – диләр алар.

Берлинда Плетцензее төрмәсендә аларның гомерләре өзелә.

А. б. Китабыбызның 3нче өлеше "Үлеме белән җиңде үлемне" дип атала. М. Җәлилнең үзенең ачы нәфрәтен белдереп "Катыйльгә" шигырен яза.

1 укучы. (Казандагы һәйкәл- пр-я карау, шигырен сөйләү )

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,

Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,

Кирәк икән, үләм аягүрә,

Балта белән башым киссәң дә.

Чыннан да нинди горур басып тора ул!

2 укучы. (Хөкем алдыннан "-Х.Я. әсәрен карау.)

1944 елның 7 февралендә Дрезенда хәрби суд җәлилчеләрне үлем җәзасына хөкем итә. Шушы елның 25 августында М. Җ. һәм аның 11 көрәштәше җәзалап утерелә.

А. б. Муса Җәлил, Муса Җәлил,

Халкыбыз каһарманы!

Үлемсез аның исеме,

Мәңгелек аның даны.

Без бу слайдларда моабит дәфтәрләрен, аның эш урынын күрәбез."Муса Җәлил" музее 2 янәшә квартираны биләп тора, 1 нче квартирада мемориаль музей, 2нчесендә күргәзмәләр залы, М.Җәлилнең шигырьләре, фотографияләре, хатлары.

А. б. Үлеме белән җиңде үлемне ул

Үлемсезлек шушы түгелме?

Җирдә мәңге исән калыр өчен

Халкы йөрәгендә терелде.

А.б. китабыбызның 4 нче өлеше "Җәлилчеләр турниры" дип атала.

Бүгенге кичәгә йомгак ясап сорауларга җавап бирик әле.

1. Шагыйрьгә куелган мәйдан(Казан кремле)
2. Аның исемен йөртүче театр (Опера һәм балет театры)
3. Беренче шигыренең исеме(бәхет)
4. Җәлилнең туган авылы( Мостафа)
5. Әсирлеккә ничәнче елда эләгә? (1942)
6. "Хөкем алдыннан" картинасының авторы

Шагыйрьнең көрәштәше (А.Алиш)

Бүгенге кичәдә катнашуыгыз өчен рәхмәт. Әйдәгез кичәбезне М. Җәлилнең сүзләренә язылган "Дулкыннар" шигыренә язылган җыр белән тәгәллик. (Шул җырга бию башкарыла.) Бүгенге якты сөйләшүләребез аңа дога булып барсын!